## Төзүчедән

Антонимия кешеләргә бик күптәннән билгеле булган күренеш исәпләнә. Шулай булуга карамастан, ул тел белеме тарихында чагыштырмача азрак өйрәнелгән мәсьәләләрнең берсе булып тора. Рус тел белемендә һәм тюркологиядә антонимиянең теоретик проблемалары узган гасырның 60-70 нче елларыннан башлап эшкәртелә башланды. Бу өлкәдә эзләнүләрнең гамәли нәтиҗәсе буларак рус, казах, үзбәк, әзербайҗан, башкорт телләренең антонимнар сүзлекләре төзелде һәм бастырып чыгарылды.

Тел күренеше буларак татар теленең антонимнары гыйльми-теоретик яктан шулай ук аз өйрәнелгән проблемалардан исәпләнә. Татар теле антонимнарының кайбер мәсьәләләре берничә кандидатлык диссертациясе дәрәҗәсендә генә тикшерелде. Татар теленә хас антонимия күренешенең кайбер гыйльми-теоретик мәсьәләләре И.Б. Бәшированың "Татар әдәби теле. Семасиология" (2010) дигән күләмле монографиясендә шактый тулы яктыртылды. Шулай да бу юнәлештәге тикшеренүләрнең гамәли нәтиҗәсе буларак кабул ителүче телебезнең тәүге антонимнар сүзлеге фәкать 1997нчы елда гына дөнья күрә алды. Ул мәктәп укучылары һәм татар телен өйрәнүчеләр өчен тәгаенләнгән. Автор-төзүчеләр (Ф.С. Сафиуллина, Л.М. Ризванова) билгеләвенчә, анда 1000гә якын антоним парлар тупланып бирелгән. Әмма сүзлектә шактый санда антонимик мөнәсәбәт белдермәгән җенес, яшь аермалыгы буенча коррелят сүзләр *(ир – хатын, әти – әни, кыз – малай, малай – бабай, тана – үгез),* фразеологик берәмлекләр һәм сүзтезмәләр *(йомшак күңелле – каты күңелле, аз сүзле – күп сүзле, күңел табарга – күңел калырга, алга барырга – артта калырга, кара акыл – яңа акыл, котылырга – үлеп калырга)*, сүзләрнең юклык формалары *(алкогольле – алкогольсез, законлы – законсыз, маллы – малсыз, чәчле – чәчсез, ярый – ярамый, булырдай – булмастай)* урын алган. Тел антонимнары (узуаль) белән рәттән сөйләм антонимнары да *(алачык – сарай, аркасында – карамастан, аяз – буран, очынырга – пошынырга, түр – ишек төбе)* бу сүзлеккә күпләп кертелгән. Сүзлектә теркәлгән *кайтырга – килергә, кайтырга – калырга, китәргә – калырга* кебек парлар исә бөтенләе белән капма-каршылыкны белдермиләр. Болар сүзләр арасындагы антонимик мөнәсәбәтне (капма-каршылыкны) гаять киң аңлаудан килә булса кирәк. Алга таба Ф.С. Сафиуллина тарафыннан төзелгән "Антонимнар сүзлегендә" дә (2003 һәм 2005нче елларда нәшер ителгәннәр) шундый ук күренешләргә юлыгабыз. Мондый характердагы кимчелекләр һәм житешсезлекләр бу сүзлекләрнең фәнни кыйммәтен төшерә һәм гамәли кулланылышта сүзләр арасындагы капма-каршылык төшенчәсен дөрес аңлауда кыенлыклар, хәтта аңлашылмаулыклар тудыра.

Телебездә махсус төзелгән аңлатмалы һәм киң даирәле, иллюстратив материалга бай булган антонимнар сүзлеге әлегә кадәр булмады. Шуңа күрә лә без әлеге эшебездә бу бушлыкны тутыру җәһәтеннән "Татар теленең аңлатмалы антонимнар сүзлеге"н төзү тәҗрибәсен актуаль мәсьәләләрдән исәплибез.

Татар теленең антонимнарын җыеп системага салуда, капма-каршы сүзләрнең мәгънәләренә аерым-аерым аңлатма биреп, аларны җөмләләр эчендә, ягъни контекстта күрсәтүдә киң аудитория укучыларга тәкъдим ителгән бу сүзлек беренче тәҗрибә булып тора. Капма-каршы мәгънәле сүзләре булган җөмләләрне җыю эше берничә дистә елга якын бара. Бу вакыт эчендә антоним

парларның икесе дә булган һәм шуның белән бергә икесе дә бер үк сүз төркеменә караган, икесе дә я туры мәгънәдә, я күчмә мәгънәдә кулланылган җөмләләр яки кыска текстлар аерым карточкаларга теркәп барылды.

Сүзлек татар теленең лексик антонимнарын тулы килеш чагылдыруга дәгъва итми. Дәвамлы еллар барышында төрле чыганаклардан җыелган антонимик парлары мотлак булган җөмләләрдә һәм кыска текстларда, билгеле, телебездә кулланылган антонимнарның барысын да теркәп бетерү мөмкин түгел. Шуңа күрә мисалсыз (контекстсыз) антонимик парлар картотекада шактый булса да, сүзлекнең корпусына кертелмәде. Телебездә антоним парларның күп санда булуын күрсәтү теләк-ниятеннән аларның сүзлекчәсен кушымта өлешендә бирергә булдык. Антонимик парлары булган җөмләләр, кыска текстлар табыла бару хисабына картотека тулылана бара һәм алар бу сүзлекнең тулыландырылган алдагы басмаларында урын алачак.

Антонимнар халык авыз иҗатында, матур әдәбиятта, публицистикада һәм фәнни язмаларда да кулланыла. Алар төрле стилистик фигуралар, художестволы троплар төзүдә катнаша. Сүзлек укучыларны шушы тасвирлау чараларының үрнәкләре белән таныштыра. Телдәге лексик системаның мөһим булган элементын тәшкил итүче антонимия күренешен киңрәк күзаллау җәһәтеннән антоним сүзләргә нигезләнеп төзелгән әйтелмәләрне (гыйбарәләрне), оксюмороннарны, катахрезаларны һәм энантиосемияле сүзләрне дә алфавит тәртибендә кушымтада бирергә булдык.

Сүзлек лексик антонимнардан гына торганлыктан, фразеологик антонимнар сүзлеккә кертелмәде. Телебезнең капма-каршы мәгънә белдерүче фразеологик берәмлекләре күп һәм алар да аерым сүзлек булып төзелергә тиеш.

Урта мәктәп өчен татар теле буенча төзелгән программаларда лексиканы өйрәнүгә һәм укучыларның сөйләм культурасын үстерүгә зур әһәмият бирелә. Шуңа күрә сүзлек беренче чиратта татар теле укытучыларына кирәкле белешмә әсбап булып тора. Укытучы анда күпмәгънәле сүзләрне, синонимнарны, омонимнарны өйрәнү өчен өстәмә материал да таба ала.

Сүзлек кереш бүлектән, алфавит тәртибендә бирелгән сүзлек корпусыннан, кушымта буларак антонимнарга нигезләнеп төзелгән әйтелмәләр (гыйбарәләр), оксюмороннар, катахрезалар һәм энантиосемияле сүзләр исемлегеннән һәм антоним парлар сүзлекчәсеннән тора.